| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның 1 августы № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 21 октябрендәге 10 номерлы (15.10.2018 № 28, от 29.11.2018 № 35, от 01.03.2023 №1, от 10.04.2023 № 12 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шегер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 21 октябрендәге 10 номерлы (15.10.2018 № 28, от 29.11.2018 № 35, от 01.03.2023 № 1, от 10.04.2023 № 12 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;»;

2) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларын тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17 йорт административ бина, Киров ур., 23 йорт, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, Ленин урамы, 32 йорт, Шөгер авылы мәдәният йорты, Ленин урамы, 35 йорт, Шөгер участоок хастаханәсе, Горький урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорларына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Шөгер авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Н.Гафиятуллин